КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 8 июнь г.Казань № 356

Республика ярдәм фондын төзү
турында

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «Республика ярдәм фонды турында» 2017 ел, 29 май, ПУ-447 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кредит яки финанс оешмалары эшчәнлегеннән зыян күргән затларга, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән затларга ярдәм күрсәтүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Республика ярдәм фонды» унитар коммерциячел булмаган оешма төзергә (алга таба – Фонд).

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын Татарстан Республикасы исеменнән Фондның гамәлгә куючысы функцияләрен башкаручы орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

10 көн эчендә Фондның уставын расларга;

Фондны дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне фонд акчасын формалаштыруга иректе мөлкәти кертем итеп кертү өчен түбәндәге рәвештә әзерләргә:

7 599 195 кв.метр мәйдандагы, 16:50:000000:15597 кадастр санлы җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын;

Фонд эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле бүтән карарлар кабул итүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\356.docx